**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2024 елның 26 ноябре №6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 26 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. «гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга " мәсьәләсе буенча КАРАР ЧЫГАРДЫ:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары) тыш, тавыш бирү хокукына ия ,яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ булган һәр гражданнан 2025 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 69 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 53 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде - гражданнар җыенында 53 катнашучы; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды :

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Бәрлегуҗа авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа торак пункты территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары) тыш,тавыш бирү хокукына ия ,яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ булган һәр гражданнан 2025 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:дигән сорау буенча карарны кабул итәргә:

-урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ”, - кабул ителгән.

3. Адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен түбәндәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.

- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 й.

шулай ук кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы ,
гражданнар жыенында рәислек итүче: Э.И. Байдамшин